БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
8 ноябрь 2021 ел

**КАРАР**
№ 79

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне;

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген;

муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләрен һәм аның максатчан күрсәткечләрен, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләрне.

2. 2009 елның 16 апрелендәге 141 номерлы карар (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмә үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Балтач район Советының
2021 елның «8» ноябрендәге
79 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар тарафыннан бозган өчен законнарда административ җаваплылык каралган җир мөнәсәбәтләре объектларына карата җир законнарында каралган мәҗбүри таләпләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – муниципаль җир контроле).

2. Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле предметы булып түбәндәгеләр торалар:

1) юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар (алга таба – контрольдә торучы затлар) тарафыннан аларны Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында аларны бозган өчен административ җаваплылык каралган Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка хокукый актларында билгеләнгән җирләрдән файдалану өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәү (алга таба – мәҗбүри таләпләр).

2) контрольдә торучы затлар тарафыннан рөхсәт документларындагы таләпләрне һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлергә тиешле документлар таләпләрен үтәү;

3) контрольдә тотучы затлар тарафыннан тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү.

3. Балтач муниципаль районында җир мөнәсәбәтләре объектларына карата муниципаль җир контроле Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба – Контроль орган) тарафыннан башкарыла.

Контроль орган исеменнән муниципаль җир контролен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе башкара. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда вазыйфаи зат «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга һәм җаваплылыкка ия.

4. Контроль орган түбәндәгеләрнең үтәлешенә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыра:

- җир кишәрлекләрен рөхсәтсез биләп алуга, җир кишәрлекләреннән Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәт ителә торган документлардан башка файдалануга, хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, җирдән файдалану хокукын үз белдеге белән бирүгә, шулай ук җир кишәрлекләрен рөхсәтсез алыштыруга юл куймау турында җир законнары таләпләрен;

- юридик затларның җир кишәрлекләреннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын җир кишәрлекләрен арендага алу яки җир кишәрлекләрен милеккә алу хокукына яңадан рәсмиләштерү турында таләпләрне;

- җир кишәрлекләрен максатчан билгеләнеше буенча файдалану турында җир законнары таләпләрен;

- авыл хуҗалыгы җитештерүе, билгеләнгән максатларда торак һәм башка төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән мәҗбүри файдалану турында җир законнары таләпләрен (әйләнеше авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе белән бәйле башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләрен мәҗбүри файдалануга бәйле таләпләрне үтәүдән тыш);

- җир биләүчеләр, җирдән файдаланучылар һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан граждан һәм җир законнары белән билгеләнгән җир кишәрлекләрен үзләштерү вакытларын;

җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан җир кишәрлекләрен арендага алу шартнамәсе шартларын;

- җирләрне вакытында кире кайтаруны;

- җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес белешмәләр бирүне;

- җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча законнарның башка таләпләрен үтәүне.

5. Муниципаль җир контроле объектлары (алга таба – контроль объектлары) булып түбәндәгеләр тора:

хокукларына бәйсез рәвештә Балтач муниципаль районы чикләрендә урнашкан җирләр, җир кишәрлекләре һәм аларның өлешләре;

алар кысаларында мәҗбүри таләпләр, шул исәптән эшчәнлек алып баручы гамәлләр кылучы (гамәл кылмаучы) гражданнарга һәм оешмаларга карый торган таләпләр үтәлергә тиешле гражданнарның һәм оешмаларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы);

аларга карата мәҗбүри таләпләр куела торган гражданнар һәм оешмалар эшчәнлеге нәтиҗәләре.

6. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларының исәбен алуны Контроль орган тәэмин итә.

7. Муниципаль җир контроле түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Җир кодексы;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы;

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 248-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнар белән үзара хезмәттәшлеге кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1515 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

«Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары;

«Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы;

Татарстан Республикасы Җир кодексы;

«Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2015 елның 13 октябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

2016 елның 28 апрелендәге 37 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы уставы

Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2005 елның 27 декабрендәге 26 номерлы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмә;

әлеге Нигезләмә.

8. Әлеге Нигезләмә максатларында төп терминнар һәм төшенчәләр «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кулланыла.

## II. Зарар (зыян) китерү куркынычы (риск) категориясе

9. Муниципаль җир контроле профилактика чараларын һәм контроль чараларны сайлап алуны, аларны карап тотуны (шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең күләме), интенсивлыкны һәм нәтиҗәләрне билгели торган зарар (зыян) китерү куркынычы белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Зарар (зыян) китерү куркынычы белән идарә итү максатларында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль объектлары түбәндәге зарар (зыян) китерү куркынычы категорияләренең берсенә керә:

урта дәрәҗәдәге куркыныч;

җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч;

түбән дәрәҗәдәге куркыныч.

11. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларын куркынычлык категорияләренә кертү критерийлары әлеге Нигезләмәнең Кушымтасында билгеләнгән.

12. Контроль объектын куркынычның бер категориясенә кертү аның характеристикасын расланган куркыныч критерийлары белән чагыштыру нигезендә контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җир кишәрлекләрен куркыныч категориясенә керткәндә контроль орган тарафыннан шул исәптән түбәндәгеләр файдаланыла:

Ккүчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләр;

контроль һәм профилактик чаралар Контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелгән чаралар кысаларында алынган белешмәләр;

җир төзелеше нәтиҗәсендә алынган дәүләт мәгълүмат фондында булган белешмәләр.

13. Контроль объекты билгеле бер кыркыныч категориясенә кертелмәгән очракта, ул түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

14. Контроль орган контроль объектының куркынычның бүтән категориясе критерийларына туры килүе турында яисә куркыныч критерийларын үзгәрүе турында мәгълүмат кергән көннән биш эш көне эчендә контроль объектының риск категориясен үзгәртү турында карар кабул итә.

15. Контроль орган куркынычның бер категориясенә кертелгән җир кишәрлекләре исемлеген (алга таба – җир кишәрлекләре исемлеге) алып бара.

Җир кишәрлекләре исемлекләрендә түбәндәге мәгълүмат бар:

а) җир кишәрлегенең кадастр номеры яки ул булмаганда җир кишәрлегенең урнашу урыны адресы;

б) җир кишәрлеге кертелгән куркыныч категориясе;

в) җир кишәрлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар реквизитлары.

16. Куркыныч категорияләре күрсәтелгән җир кишәрлекләре исемлеге Контроль органның рәсми сайтында урнаштырыла.

17. Бирелгән куркыныч категориясенә карап, планлы контроль чараларының түбәндәге төрләре һәм периодик рәвештә кабатлануы билгеләнә:

урта дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата - 3 елга бер планлы контроль чара;

җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата - 5 елга бер планлы контроль чара;

Түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль чаралар үткәрелми.

## III. Зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау

18. Профилактика чаралары Контроль орган тарафыннан контрольдә торучы затларның мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүгә китерердәй шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү һәм мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затларга җиткерү, аларны үтәү ысулларын үтәү максатларында гамәлгә ашырыла.

19. Профилактик чаралар ел саен Контроль орган тарафыннан раслана торган закон тарафыннан саклана торган Кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук әлеге Программада каралмаган профилактик чаралар үткәрелергә мөмкин.

20. Муниципаль җир контролен тормышка ашырганда түбәндәге профилактик чаралар үткәрелә:

мәгълүмат бирү;

хокук куллану практикасын гомумиләштерү;

кисәтү белдерү;

консультация бирү;

профилактик визит.

21.Мәгълүмат бирү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 3 өлешендә каралган белешмәләрне һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Контроль орган әлеге мәгълүматларны актуаль хәлдә тотарга тиеш.

22. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль орган тарафыннан елга 1 тапкыр үткәрелә һәм түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелә:

1) Контроль орган һәм аның вазыйфаи затлары тарафыннан муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен, мәҗбүри таләпләрне куллануга бертөрле карашларны тәэмин итү;

2) күрсәтелгән бозулар барлыкка килүгә ярдәм итүче мәҗбүри таләпләрне, сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бер типтагы бозуларны ачыклау;

3) закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү очракларын анализлау, зарар (зыян) китерүнең чыганакларын һәм куркыныч (риск) факторларын ачыклау;

4) мәҗбүри таләпләрне актуальләштерү турында тәкъдимнәр әзерләү;

5) дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү.

23. Балтач муниципаль районында җир контролен гамәлгә ашыруның хокук куллану практикасын гомумиләштерү үткәрелгән контроль чаралар һәм

аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматларны җыю һәм анализлау ярдәмендә Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча, контроль орган хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган доклад әзерли.

Хокук куллану практикасы турында доклад Контроль орган күрсәтмәсе белән раслана, контроль орган рәисе тарафыннан имзалана һәм хисап елынан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырыла.

24. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү (алга таба – кисәтү) Контроль органда мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булу турында белешмәләр булган очракта һәм (яисә) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүе яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаган очракта, контрольдә торучы затка белдерелә.

Кисәтү Контроль орган җитәкчесе тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләр алынганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча белдерелә.

25. Кисәтүдә аларның норматив-хокукый актын күздә тоткан тиешле мәҗбүри таләпләрне күрсәтү, контрольдә торучы затның мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә алган яки китерә торган конкрет нинди гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрү турында тәкъдим булырга тиеш һәм анда контрольдә торучы зат тарафыннан белешмәләр һәм документлар тапшыру таләбе була алмый.

Кисәтү язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә, теркәү номеры бирелгән кисәтүләрне исәпкә алу журналында теркәлә һәм контрольдә торучы зат адресына җибәрелә.

26. Контрольдә торучы зат кисәтүгә карата кисәтү алган көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча кире кагу белдерергә хокуклы.

Кире кагуда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) юридик затның исеме, шәхси эшкуарның, гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

2) юридик затның, шәхси эшкуарның - салым түләүченең идентификация номеры;

3) паспорт яки шәхесне раслый торган башка документның сериясе һәм номеры, яшәү урыны, элемтә өчен телефон (гражданнар өчен);

4) контрольдә торучы зат адресына җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

5) контрольдә торучы затның кисәтүдә күрсәтелгән мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган яисә китерә алган гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата позицияне нигезләү.

Контроль органга кире кагулар контрольдә торучы зат тарафыннан җибәрелә

почта аша кәгазьдә яисә Контроль органның электрон почта адресы яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка ысуллар белән 248-ФЗ номерлы федераль закон белән билгеләнгән очракларда, гади электрон имза яисә көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

Контроль орган кире кагуларны карый, карау нәтиҗәләре буенча контрольдә торучы затка кире кагулар алган көннән алып 20 эш көне эчендә килешү турында җавап яки кире кагу белән нигезле килешмәүне җибәрә.

Кире кагуда тәкъдим ителгән дәлилләрне кабул иткән очракта Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) элек җибәрелгән кисәтүне юкка чыгара, бу хакта игълан ителгән кисәтүләр журналында тамга ясала.

Тиешле нигезләмәләрне күрсәтеп, кире кагу белән килешмәү турында мәгълүмат яисә кисәтүне юкка чыгару турында мәгълүмат контрольдә торучы зат адресына язмача яки электрон документ формасында җибәрелә.

Кире кагуларны карау нәтиҗәләре мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны оештыру һәм уздыру, муниципаль җир контролен оештырганда һәм гражданнарның, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган башка максатларда риск-юнәлешле якын килүне куллануны камилләштерү максатларында Контроль орган тарафыннан кулланыла.

27. Муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр бирү Контроль органның вазыйфаи затлары тарафыннан контрольдә тоһучы затларның һәм аларның вәкилләренең мөрәҗәгатьләре буенча телефон аша, видео-конференц-элемтә ярдәмендә, шәхси кабул итүдә яки профилактик чара, контроль чара уздыру барышында, шулай ук язма рәвештә бирелә.

Шәхси кабул итү Контроль органы җитәкчесе тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштырыла.

Контроль орган консультация бирүжурналы алып бара.

28. Консультация бирү телдән яки язма рәвештә түбәндәге мәсьәләләр буенча башкарыла:

а) муниципаль җир контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру;

б) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

в) Контроль орган карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

г) үтәлешен бәяләү Контроль орган тарафыннан контроль чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу;

29. Язма рәвештә консультация бирү Контроль органның вазыйфаи заты тарафыннан түбәндәге очракларда башкарыла:

а) контрольдә торучы зат тарафыннан консультация бирү мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язма гарызнамә бирелде;

б) консультацияләр бирү вакытында куелган сорауларга җавап бирү мөмкин түгел;

в) куелган сорауларга җавап өстәмә белешмәләр соратып алуны таләп итә.

30. Контроль орган контрольдә торучы затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

Контрольдә торучы зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вакытларда язмача җавап бирү турында гарызнамә җибәрергә хокуклы.

31. Консультация биргәндә Контроль органның вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнары нигезендә һәркем файдалану мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш.

Консультация биргәндә түбәндәгеләр бирелә алмый:

контроль органы вазыйфаи затларының, контроль чарада катнашучыларның конкрет чарасын, карарларын һәм (яки) гамәлләрен бәяләгән мәгълүмат;

контроль чара кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынаулар нәтиҗәләре.

Консультация барышында Контроль органның вазыйфаи затына мәгълүм булган мәгълүмат контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча аларны бәяләү максатларында кулланыла алмый.

32. Контроль органга контрольдә торучы затларның һәм аларның вәкилләренең 5 һәм аннан күбрәк бертиптагы мөрәҗәгатьләре кергән очракта, консультация бирү Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган язма аңлатманы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән башкарыла.

33. Профилактик визит контрольдә торучы затның эшчәнлек алып бару урыны буенча профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдә торучы затка үз эшчәнлегенә яисә үз карамагындагы контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч (риск) критерийларына туры килүе, нигезләр һәм куркыныч (риск) категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары турында, шулай ук аның аларны тиешле куркыныч (риск) категориясенә кертүдән чыгып, контроль объектына карата үткәрелә торган контроль чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында хәбәр ителә.

Профилактик визитны үткәргәндә, контроль объектлары закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зарар (зыян) китерү куркынычы тудырганы яки мондый зарар (зыян) китергәне билгеле булса, Контроль органының вазыйфаи заты үткәрелгән профилактик визит турында хисап рәвешендә контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, Контроль орган җитәкчесенә бу хакта кичекмәстән хәбәр итә.

34. Мәҗбүри профилактик визит җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәү белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыруны башлаучы контрольдә торучы затларга карата, мондый эшчәнлек башланганнан бирле, бер ел дәвамында үткәрелә.

Контроль орган мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында аны үткәрү датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча контрольдә торучы затка хәбәр итә.

Мәҗбүри профилактик визитны үткәрү турында хәбәрнамә язма рәвештә яисә электрон документ формасында төзелә һәм түбәндәге белешмәләр үз эченә ала:

1) хәбәрнамәне төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) Контроль орган исеме;

3) контрольдә торучы затның тулы исеме;

4) вәкаләтле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

5) мәҗбүри профилактик визитның датасы, вакыты һәм урыны;

6) вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә контрольдә торучы зат адресына язма яки электрон документ формасында җибәрелә.

Контрольдә торучы зат, мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә җибәргән Контроль органга мәҗбүри профилактик визитны үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, мәҗбүри профилактик визит уздырудан баш тартырга хокуклы.

Мәҗбүри профилактик визитны үткәрү вакыты Контроль орган тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

## IV. Контроль чаралар

35. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда Контроль орган тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында түбәндәге контроль чаралар һәм контроль гамәлләр үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты (карау, сораштыру, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яисә контроль объектның урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны сорату, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерүләр ярдәмендә);

б) рейд тикшерүе (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны сорату, инструменталь тикшерүләр, экспертиза ярдәмендә);

в) докумен тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертизалар үткәрү юлы белән);

г) урынга чыгып тикшерү (карау, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар срату, инструменталь тикшерү юлы белән);

д)мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (җирләр, җир кишәрлекләре һәм аларның өлешләре турында булган мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән, муниципаль хезмәтләрне һәм функцияләрне үтәү кысаларында алынган, мәгълүматларны, шулай ук дәүләт, муниципаль һәм ведомство мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне анализлау юлы белән);

е) урынга чыгып тикшерү (карау, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып) юлы белән).

Әлеге пунктта каралган контроль чаралар һәм контроль гамәлләр төрләре күрсәтелгән чаралар кысаларында конкрет контроль объектының ТР Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәнең кушымтасы нигезендә билгеле бер куркыныч (риск) категориясенә кертелүенә бәйле рәвештә дифференцияләнми.

Планнан тыш тикшерү чаралары төрләре, әлеге Нигезләмәнең 41 пунктында билгеләнгән контроль чараны үткәрү нигезләренә бәйле рәвештә билгеләнә.

36. Контроль чаралар барышында түбәндәге контроль гамәлләр гамәлгә ашырыла:

а) карау;

б) сораштыру;

в) язма аңлатмалар алу;

г) документлар сорату;

д) инструменталь тикшерү;

е) экспертиза.

Контроль гамәлләр үткәрү тәртибе 248-ФЗ номерлы Федераль законның 14 бүлеге белән җайга салына.

37. Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек түбәндәге контроль чаралар үткәргәндә гамәлгә ашырыла:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) урынга чыгып тикшерү.

38. Түбәндәге контроль чаралар контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнешсез үткәрелә:

а) контроль таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

б) урынга чыгып тикшерү.

39. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында түбәндәге планлы тикшерү чаралары үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) урынга чыгып тикшерү.

40. Муниципаль җир контролен тормышка ашыру кысаларында түбәндәге планнан тыш тикшерү чаралары үткәрелергә мөмкин:

а) инспекция визиты;

б) рейд тикшерүе;

в) документар тикшерү;

г) урынга чыгып тикшерү;

д) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;

е) урынга чыгып тикшерү.

41. Контрольдә торучы зат белән үзара бәйләнештә үткәрелә торган контроль чаралар үткәрү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) Контроль органда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яисә зарар (зыян) китерү куркынычы турында белешмәләр булу яки контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүен яки контроль объектының мондый параметрлардан тайпылуын ачыклау;

б) контроль чаралар үткәрү планына кертелгән контроль чараларны үткәрү вакытлары җитү;

в) конкрет контрольдә торучы затларга карата контроль чаралар үткәрү турында Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәсе;

г) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклауга күзәтчелек кысаларында контроль чара үткәрү турында прокурор таләбе;

42. Контроль чаралар Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи затларының биремнәре, Контроль органның эш планындагы биремнәрне дә кертеп, шул исәптән 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үзара бәйләнешсез үткәрелә.

43. Контроль чара, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүдән һәм урынга чыгып тикшерүдән тыш, шулай ук реестр операторы теркәгән Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрының эшкә яраксызлыгы очракларыннан тыш, аны формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре белән билгеләнгән Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына керткәннән соң башланырга мөмкин.

44. Контрольдә торучы зат яисә аның вәкиле барында үткәрелергә тиешле, үзара хезмәттәшлекне таләп итми торган контроль чаралар үткәрүдән, контроль гамәлләр кылудан тыш, контроль чаралар үткәргәндә һәм контроль гамәлләр кылганда.

Контрольдә торучы зат яисә аның вәкиле булмаган очракта, контрольдә торучы зат тарафыннан Контроль органга контроль чарасны үткәрүдә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат биргән очракта, әгәр контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәүгә бәя контрольдә торучы зат катнашыннан башка үткәрелергә мөмкин, ә контрольдә торучы затка контроль

чара үткәрү турында тиешенчә хәбәр ителгән булса, контроль эшләр башкарыла.

45. Контрольдә торучы затлар булган шәхси эшкуар, граждан Контроль органга контроль чараны уздырганда булмау турында түбәндәге очракларда мәгълүмат бирергә хокуклы:

1) медицина учреждениесендә стационар дәвалануда булу;

2) Россия Федерациясеннән читтә булу;

3) административ арест;

4) җинаять кылуда шикләнелүчегә физик затка карата чик кую чараларын сайлап алу: чыгып китмәү һәм үз-үзеңне тиешенчә тоту турында подписка, билгеле бер гамәлләрне тыю, сак астына алу, йорт арестына алу;

5) контроль (күзәтчелек) чараларын үткәргәндә затның катнашуына комачаулаучы җиңеп булмастай көчле шартлар башлану (хәрби гамәлләр, һәлакәт, табигать бәла-казасы, зур авария, эпидемия һәм башка гадәттән тыш хәлләр).

Контроль чараны үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында мәгълүмат килеп ирешкәндә, аны үткәрү вакыты Контроль орган тарафыннан шәхси эшкуарның, гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

46. Җиңеп булмастай көчле шартлар килеп туган очракта, контрольдә торучы зат контроль орган адресына үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиешле мәгълүматны җибәрә:

а) җиңеп булмастай көчле шартларны һәм аларның дәвамлылыгын тасвирлау;

б) контроль (күзәтчелек) чарасы уздырганда барлыкка килгән җиңеп булмастай көчле шартлар барлыкка килү һәм чарада катнашмау яисә тоткарланып килү арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше турында белешмәләр;

в) контроль (күзәтчелек) чараны үткәргәндә катнашуга комачаулаучы хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытны күрсәтү.

Күрсәтелгән мәгълүмат бирелгәндә контроль чараны үткәрү вакыты Контроль орган тарафыннан шәхси эшкуарның, гражданның әлеге мөрәҗәгатенә сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

47. Муниципаль җир контролен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Контроль орган түләүсез нигездә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, шул исәптән электрон формада, алар карамагында булган документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка органнардан яисә күрсәтелгән органнарга караган оешмалардан документлар һәм (яки) белешмәләр ала. Күрсәтелгән документлар һәм (яки) белешмәләр исемлеге, аларны бирү тәртибе һәм вакытлары «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2021 елның 6 мартындагы 338 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен оештырганда һәм гамәлгә ашырганда, контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан алына

торган карамагында документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка органнардан яисә күрсәтелгән органнарга караган оешмалардан документлар һәм (яки) белешмәләр алу тәртибендә билгеләнгән.

48. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга һәм гражданнарга карата планлы контроль чаралар «Чираттагы календарь елына планлы контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрү планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән, килештерү, аңа ел дәвамында контроль (күзәтчелек) чараларын кертү һәм аннан төшереп калдыру тәртибе турында» 2020 елның 31 декабрендәге 2428 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Чираттагы календарь елына планлы контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрү планын формалаштыру, аны прокуратура органнары белән, килештерү, аңа ел дәвамында контроль (күзәтчелек) чараларын кертү һәм аннан төшереп калдыру тәртибе нигезендә эшләнә торган планлы контроль чаралар үткәрүнең еллык планы нигезендә үткәрелә.

49. Контроль органының вазыйфаи затлары һәм контроль гамәлләр кылуга җәлеп ителгән затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны дәлилләү өчен контроль чара үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан үткәрелә торган фотога төшерү һәм/яисә аудио- һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләр кулланылырга мөмкин.

Фотога төшерүне, аудио - һәм видеоязмаларны, контроль чараларны гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәүнең бүтән ысулларын куллану зарурлыгы турында карар Контроль органның вазыйфаи заты тарафыннан мөстәкыйль кабул ителә.

Фотога төшерү, аудио - һәм видеоязмалар ясау мәҗбүри рәвештә контрольдә торучы затка хәбәр итеп башкарыла.

50. Фотога төшерү ярдәмендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны теркәү кимендә ике фотосурәт белән башкарыла. Фотога төшерү нокталары һәм юнәлешләре аңа карата контроль чара үткәрелгән җир мөнәсәбәтләре объекты схемасында билгеләнә. Контроль чараларны үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне үтәү (бозу) дәлилләрен теркәү өчен кулланыла торган фотога төшерү һәм видеоязма җитәрлек яктыртылган шартларда башкарылырга тиеш.

Аудио - һәм видеоязма контроль чара барышында, яздыру башында һәм ахырында датасы, урыны, башлану һәм тәмамлану вакыты турында хәбәр итеп, өзлексез башкарыла. Яздыру барышында мәҗбүри таләпләрне бозуның урыны һәм характеры җентекләп теркәлә һәм күрсәтелә.

51. Фотога төшерү, аудио һәм видеоязмалар, геодезия һәм картометрик үлчәүләр һәм бу максатлар өчен кулланылган техник чаралар турында мәгълүмат контроль чара нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта һәм контроль чара кысаларында үткәрелә торган контроль эш нәтиҗәләре буенча төзелә торган беркетмәдә чагыла.

Фотога төшерүне һәм видеоязмаларны мәҗбүри таләпләрне бозуның дәлилләрен теркәү өчен куллану дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Фотога төшерү, аудио - һәм видеоязма ясау нәтиҗәләре контроль чара актына кушымта булып тора.

Контроль чаралар барышында инструменталь тикшерүләр Контроль органның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла торган геодезик үлчәүләр (билгеләмәләр) һәм (яки) картографик үлчәүләр уздыру юлы белән башкарыла.

52. Инспекция визиты конкрет контрольдә торучы зат һәм (яки) контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча хуҗасы (кулланучы) белән үзара хезмәттәшлектә башкарыла.

Инспекция визиты контрольдә торучы затка һәм контроль объектының милекчесенә алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

Инспекция визитын үткәрү эшчәнлек алып баруның бер урында яисә бер контроль объектында бер эш көненнән дә озак булмаска тиеш.

Контрольдә торучы затлар яки аларның вәкилләре Контроль органның вазыйфаи затының биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

53. Рейд тикшерүе контроль объектына ия булучы, аннан файдаланучы яки аның белән идарә итүче контрольдә торучы затларның теләсә нинди санына карата, алар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

Рейд тикшерүе үткәрү контроль чараларыны үткәрүгә җәлеп ителә торган (кирәк булганда) экспертлар, белгечләр катнашында контроль чара үткәрү турында карар нигезендә уртак (ведомствоара) контроль чара формасында (кирәк булганда) башкарыла.

Рейд тикшерүе вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш. Рейд тикшерүе вакытында бер контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек итү вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

Рейд тикшерүе куздырганда Контроль органның вазыйфаи затлары контроль объектында булган затлар белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы.

Контрольдә торучы затлар рейд тикшерүе барышында вәкаләтле вазыйфаи затларның контроль объектларына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

Рейд тикшерүе барышында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, Контроль органның җаваплы вазыйфаи заты урында ук хокук бозуга юл куйган һәр контрольдә торучы затка карата акт төзи, шул ук вакытта контрольнең барлык нәтиҗәләренә карата мәгълүматны үз эченә алган аерым акт рәсмиләштерелми.

54. Документар тикшерү Контроль органның урнашу урыны буенча үткәрелә, аның предметы булып бары тик контрольдә торучы затлар документларында булган, аларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган белешмәләр, шулай ук аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда кулланыла торган һәм Контроль органның мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәү белән бәйле, контрольдә торучы затның (аның

филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча урнашкан документлар гына тора.

Документар тикшерү барышында Контроль орган карамагында булган контрольдә торучы затларның документлары, алдагы контроль чаралар нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм муниципаль җир контроленең әлеге контрольдә торучы затларына карата башкарылган эш нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

Контроль органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса яки бу белешмәләр контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, Контроль орган контрольдә торучы зат адресына документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбен җибәрә.

Контрольдә торучы зат таләп алынганнан соң ун эш көне эчендә Контроль органга әлеге документларны тапшырырга бурычлы.

55. Әгәр дә документар тикшерү барышында контрольдә торучы зат биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган булса, әлеге документларда булган белешмәләрнең Контроль органда булган документлардагы һәм (яки) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, хаталар, каршылыклар һәм белешмәләрнең туры килмәве турында мәгълүмат ун эш көне эчендә кирәкле аңлатмаларны тапшыру таләбе белән контрольдә торучы затка җибәрелә.

Контрольдә торучы зат, таләп ителә торган аңлатмалардан тыш, Контроль органга өстәмә рәвештә элек бирелгән документларның дөреслеген раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Документар тикшерү уздырганда документар тикшерү предметына карамаган белешмәләр һәм документлар, шулай ук Контроль орган тарафыннан башка органнардан алына торган белешмәләр һәм документлар контрольдә торучы заттан соратылмый.

56. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш.

Контроль орган тарафыннан контрольдә торучы затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру таләбе җибәрелгән вакыттан алып таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органга тапшырганчы кадәр чор, шулай ук контрольдә торучы затка Контроль органның контрольдә торучы зат тапшырган документларда ачыкланган хаталар турында һәм (яки) каршылыклар турында яисә бу документларда булган белешмәләрнең Контроль органда булган документлардагы белешмәләргә һәм (яки) муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве турында мәгълүматны һәм кирәкле аңлатмаларны язма рәвештә бирү таләпләрне җибәргән вакыттан күрсәтелгән аңлатмаларны Контроль органга тапшырганчыга кадәр чор күрсәтелгән вакытка кертелми.

57. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килешмичә генә үткәрелә.

58. Урынга чыгып тикшерү контроль объектларга ия булган һәм (яки) алардан файдаланучы конкрет контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлек юлы белән мондый зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү, шулай ук Контроль орган карарларының үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

Урынга чыгып тикшерү контрольдә торучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яки контроль объектының урнашкан (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

59. Урынга чыгып тикшерү түбәндәгеләр мөмкин булмаган очракта үткәрелә:

1) Контроль орган карамагында булган яки ул соратып ала торган документларда һәм контрольдә торучы затның аңлатмаларында булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген дәлилләп булмаганда;

2) урынга чыкмыйча контрольдә торучы затның эшчәнлегенең, гамәлләренең (гамәл кылмавының) һәм (яки) аның карамагындагы һәм (яки) ул файдаланучы контроль объектларының әлеге Нигезләмәнең 58 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләп һәм контроль чараларның башка төре кысаларында каралган кирәкле контроль гамәлләр кылып булмый.

60. Планнан тыш тикшерү, аны 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары, 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә үткәрү очракларыннан тыш, бары тик прокуратура органнары белән килешү буенча гына үткәрелергә мөмкин.

Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында контрольдә торучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында каралган тәртиптә, урынга чыгып тикшерү башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча аны үткәрү турында карарның күчермәсен җибәрү юлы белән, Федераль закон белән башкасы каралмаган булса, хәбәр ителә.

61. Урынга чыгып тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата урынга чыгып тикшерү барышында үзара хезмәттәшлекнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

62. Урынга чыгып тикшерү контрольдә торучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

Урынга чыгып тикшерү оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) урнашкан (эшчәнлек алып бару) урыны буенча, гражданның эшчәнлек алып бару урыны буенча, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдә торучы зат белән хезмәттәшлек итү рөхсәт ителми.

Урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында каралган карарлар кабул ителә алмый.

Бер объектны (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектны) чыгып тикшерү уздыру вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

63. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) Контроль органда булган контроль объектлары турында мәгълүматларны, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контрольдә торучы затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүматларны, һәркем файдалана алырлык булган башка мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләре булган хокук бозуларны теркәүнең автоматлаштырылган техник чараларыннан файдаланып алынган мәгълүматларны җыюдан, анализлаудан гыйбарәт.

Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингы вакытында), контрольдә торучы затларга мәҗбүри таләпләрдә билгеләнмәгән бурычлар йөкләнә алмый.

Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү яки зарар (зыян) китерү куркынычы янау фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне бозарга әзеләнүләр турында яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Контроль орган тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

1) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы нигезендә планнан тыш контроль чара үткәрү турында карар;

2) кисәтү игълан итү турында карар.

64. Әлеге Нигезләмәнең 37 пунктында күрсәтелгән контроль чараларны үткәрү тәмамланганнан соң, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән конкрет контроль чара өчен билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә контроль чара акты төзелә.

Ачыкланган хокук бозулар бетерелгән очракта, актта контроль чарасны үткәрү тәмамланганчы, аны бетерү факты күрсәтелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозу дәлилләре булган документлар, башка материаллар актка беркетелергә тиеш. Контроль чараларны үткәргәндә тутырылган тикшерү кәгазьләре актка теркәлә.

Актны рәсмиләштерү мондый чараны үткәрү көнендә контроль чара үткәрү урынында башкарыла.

Дәүләт, коммерция, хезмәт яки закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итүче контроль чара нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

Прокуратура органнары тарафыннан килештерелгән контроль чара акты прокуратура органнарына Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестры ярдәмендә җибәрелә.

65. Контроль чаралар турында мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында урнаштырыла.

66. Контрольдә торучы зат яки аның вәкиле актның эчтәлеге белән контроль чараны үткәрү урынында таныша.

Контрольдә торучы зат белән үзара хезмәттәшлексез генә документар тикшерү яки контроль чара үткәрү очрагында, шулай ук, әгәр дә актны контроль чара нәтиҗәләре буенча аны үткәрү урынында экспертиза үткәрү аркасында төзү мөмкин булмаса, Контроль орган актны контрольдә торучы затка 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Контрольдә торучы актка әлеге актны әзерләгән ысул белән имза куя. Контрольдә торучы зат яки аның вәкиле имза куюдан баш тартканда яисә имза куярга мөмкинлек булмаганда, контроль чара үткәрү нәтиҗәләре буенча актта тиешле тамга ясала.

Контроль чара актында бәян ителгән фактлар һәм нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, контрольдә торучы зат әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә каралган тәртиптә шикаять җибәрергә хокуклы.

67. Контроль чара үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланмаган очракта, бу хакта белешмәләр Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына кертелә.

Контроль органның вазыйфаи заты мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча киңәшләр бирергә, законда саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

Контроль чара үткәргәндә контрольдә торучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, Контроль орган Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

1) законда саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау яисә зарар (зыян) китерүне туктату буенча һәм әгәр контроль чараны үткәргәндә контроль объектына ия булган һәм (яисә) аннан файдалана торган гражданның, оешмаларның эшчәнлеге закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зарар (зыян) китерү куркынычы янаса яисә мондый зарар (зыян) китерелсә, гражданнар, оешмалар игътибарына теләсә нинди мөмкин булган ысул белән закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы булу турында һәм аны булдырмау ысуллары турында мәгълүмат җиткерү буенча законнарда каралган чараларны кичекмәстән күрергә тиеш;

2) аларны бозган өчен Россия Федерациясе законнарында административ яки җинаять җаваплылыгы каралган җир законнарын бозу очракларын

ачыклаганда, контроль чара акты күчермәсен дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрергә;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне контрольдә тоту, закон бозуларны кисәтү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүне булдырмау буенча чаралар күрергә;

4) мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирү, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалауга юнәлдерелгән башка чаралар үткәрү турында мәсьәләне карарга.

## V. Контроль органның карарларына, Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү

68. Контроль органның карарларына, муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

69. Контроль органның карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирелгәннән соң гына судка шикаять бирелергә мөмкин, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан судка шикаять бирү очракларыннан тыш.

70. Муниципаль җир контрольне гамәлгә ашыру кысаларында аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре, алар фикеренчә, турыдан-туры бозылган контрольдә торучы затлар түбәндәгеләргә судка кадәр шикаять бирүгә хокуклы:

а) контроль чаралар үткәрү турында карарлар;

б) контроль чаралар актлары;

в) контроль чаралар кысаларында Контроль органның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына).

71. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып, Контроль органга тапшырыла.

Граждан шикаять тапшырганда, ул гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять, контрольдә торучы зат тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланмыйча, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып басма чыганакта тапшырыла.

72. Контроль органның карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Контроль орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Контроль орган җитәкчесенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан карала.

73. Контроль органның карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдә торучы зат үз хокукларының бозылуы турында белгән яисә белергә тиеш булган көннән соң утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү вакыты нигезле сәбәпләр аркасында үткәргән очракта, шикаять бирүче зат үтенечнамәсе буенча әлеге вакыт Контроль орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаятьне биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне кабат шул ук нигезләр буенча җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә Контроль органның шикаять белдерелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенечнамә булырга мөмкин.

74. Шикаятьне теркәгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча Контроль орган түбәндәгеләр турында карар кабул итә:

1) Контроль органның шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Контроль органның шикаять бирелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турында үтенечнамә буенча карар хакында мәгълүмат карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

75. Шикаять үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) Контроль органның исеме, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), аларга шикаять бирелә торган карар һәм (яки) гамәлләр (гамәл кылмау);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны (эшчәнлек алып бару урыны) турында белешмәләр яисә мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашу урыны турында белешмәләр, яисә ышанычнамә реквизитлары, ышанычнамә буенча шикаять бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), шикаятьне карау вакытында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыруның теләгән ысулы һәм аның буенча карарны алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китерә яисә китерә ала торган Контроль органның шикаять бирелә торган карары һәм (яки) аның вазыйфаи затының гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче алар нигезендә Контроль орган карары һәм (яки) вазыйфаи затның гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган нигезләр һәм дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган

документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин;

5) шикаять биргән зат таләпләре;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, шикаять бирелә торган Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында контроль чараның исәп номеры.

Шикаятьтә әдәпсез яки мәсхәрәле сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булырга тиеш түгел.

Аңа тиешле хокук бирелгән очракта, шикаять бирү контрольдә торучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Шикаятькә Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле Вәкилнең, аның иҗтимагый вәкиленең, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең шикаятькә кагылышлы позициясе беркетелергә мөмкин.

Эшкуарлар хокукларын яклау буенча Россия Федерациясе Президенты каршындагы Вәкаләтле Вәкилнең, аның иҗтимагый вәкиленең, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең позициясенә җавап шикаять биргән Контроль орган тарафыннан шикаять буенча карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә җибәрелә.

76. Контроль органның җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаять алган мизгелдән биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә, әгәр:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 73 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү вакыты тәмамланганнан соң бирелгән һәм аны торгызу турында яки шикаять бирүнең үткән вакытын торгызуга үтенечнамәләр юк;

2) шикаять бирүнең үткән вакытын торгызу турында үтенечнамәне канәгатьләндерүдән
баш тартылган;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны биргән контрольдә торучы заттан шикаятьне кире алу турында гариза кергән;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары бар;

5) элек шул ук контрольдә торучы затлар тарафыннан шул ук нигезләр буенча Контроль органга башка шикаять бирелгән;

6) шикаятьтә әдәпсез яки мәсхәрәле сүзләр, Контроль органның вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар бар;

7) элегрәк әлеге контрольдә тотучы затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук мәсьәлә буенча

шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту алынды һәм яңа дәлилләр яисә шартлар китерелми;

8) шикаять тиеш булмаган Контроль органга тапшырылган;

9) Россия Федерациясе законнарында Контроль органы карарларына суд тәртибе шикаять бирү генә каралган.

әлеге пунктның 3-8 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка шикаять бирү өчен нигез була алмый.

77. Контроль органның шикаятьне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасын куллана, шикаятьне карау дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче документлар белән мәгълүматлар белән бәйле очраклардан тыш.

Контроль орган контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләр тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, дәүләт яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасын кулланмыйча, Контроль орган җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

78. Шикаять контроль орган тарафыннан аны теркәгән көннән соң егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аерым очракларда күрсәтелгән вакыт күрсәтелгән орган тарафыннан озайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артык түгел.

79. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан өстәмә мәгълүмат һәм шикаять предметына караган документлар соратып алырга хокуклы.

Контрольдә торучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны гарызнамә җибәргәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау вакыты узу шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында гарызнамә җибәргәннән алып Контроль орган аларны алганчы туктатыла, ләкин гарызнамә җибәргәннән соң биш эш көненнән дә артык түгел.

Контрольдә торучы заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар алу шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

Шикаять биргән контрольдә торучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынган оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаятьне биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче, үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

80. Кабул ителгән карарның һәм кылынган гамәлнең (гамәл кылмауның) законлылыгын һәм нигезлелеген раслау бурычы вазыйфаи затының карарына һәм гамәл кылуына (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Контроль органга йөкләнә.

81. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерми калдыра;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча гамәлдән чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән, кирәк булганда, билгеле бер гамәлләрне гамәлгә ашыру турында карар чыгара.

82. Кабул ителгән карарның нигезе, аны үтәү вакыты һәм тәртибе булган Контроль орган карары кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдә торучы затның шәхси кабинетында урнаштырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Контроль орган карары контрольдә торучы затка, дәүләт яисә закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә басма чыганакта җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
территориясендә муниципаль җир
контроле турында Нигезләмәгә
кушымта

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда аның хокук иясе булган гражданнар, юридик затлар һәм (яки) шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла торган җир кишәрлекләрен билгеле бер куркыныч (риск) категориясенә кертү критерийлары**

1. Урта дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә түбәндәгеләр керә:

а) житештерү һәм куллану калдыкларын күмү һәм урнаштыру, зиратлар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре белән чиктәш җир кишәрлекләре;

б) гомуми кулланылыштагы су объектларының яр буе полосасы чикләрендә урнашкан яки аның янәшәсендәге җир кишәрлекләре.

2. Җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә түбәндәге җир кишәрлекләре керә:

а) торак пунктлар җирләре категориясенә кергән һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, урман фонды җирләре, аеруча саклана торган территорияләр һәм объектлар җирләре, запас җирләр категориясенә караган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре белән чиктәш;

б) сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә кергән, автомобиль юлларын, тимер юлларны, труба үткәргеч транспортны, электр линияләрен урнаштыру өчен билгеләнгән җирләрдән тыш, һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре белән чиктәш җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре;

в) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә кергән һәм торак пункт җирләре категориясенә караган җирләр һәм (яки) җир кишәрлекләре белән чиктәш.

3. Түбән дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә урта дәрәҗәдәге яисә җиңелчә дәрәҗәдәге куркыныч категориясенә кертелмәгән барлык башка җир кишәрлекләре керә.

Балтач район Советының
2021 елның «8» ноябрендәге
79 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Контроль чара үткәрү нәтиҗәсендә билгеләнгән контрольдә торучы зат тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлеге мәйданының Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган белешмәләрдәге җир кишәрлеге мәйданына туры килмәве.

2. Контрольдә торучы зат тарафыннан җир кишәрлегеннән факттагы файдалану Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган белешмәләрдәге җир кишәрлегеннән файдалану максатына туры килмәү.

3. Җир кишәрлеген бирү вакытыннан алып өч елдан артык вакыт узуга карамастан җир кишәрлеге озак вакыт үзләштерелми яисә җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү вкыты тәмамланган, ә җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр (капиталь төзелеш объектының булмавы, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану һәм аны бирү шартлары нигезендә төзелеш эшләре алып бару һәм аннан файдалану буенча башка гамәлләр башкару) күзәтелми.

4. Җир кишәрлекләрен файдалану өчен нигез булып торган документларны рәсмиләштерүгә карата мәҗбүри таләпләрне үтәмәү.

Балтач район Советының
2021 елның «8» ноябрендәге
79 номерлы карарына
кушымта

## Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм индикатив күрсәткечләре[1]

| **Төп күрсәткечләр** | **Максатчан күрсәткечләр** |
|---|---|
| Ачыкланган җир законнарын бозу очракларыннан бетерелгән бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләр кылуына (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең проценты | 0% |
| Контроль чараларның бетерелгән нәтиҗәләренең проценты | 0% |
| Административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында чыгарылган суд карарлары проценты | 95% |
| Муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми санынннан административ хокук бозулар турында эшләр буенча суд тәртибендә гамәлдән чыгарылган карарлар проценты | 0% |

| **1.** | **Үткәрелгән чаралар параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.1. | Планлы (рейд) биремнәрнең (караулар) үтәлеше | Врз = (РЗф / РЗп) x 100 | Врз - планлы (рейд) биремнәрнең (караулар) үтәлеше %<br>РЗф - үткәрелгән планлы (рейд) биремнәр (караулар) саны (бер.)<br>РЗп - расланган планлы (рейд) биремнәр (карау) саны (бер.) | 100 % | Расланган планлы (рейд) биремнәр (караулар) |
| 1.2. | Планнан тыш тикшерү үтәлеше | Ввн = (Рф / | Ввн - планнан тыш тикшерү үтәлеше | 100 % | Контроль органга кергән хатлар |

[1] *Контроль төренең күрсәтелгән төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, индикатив күрсәткечләр үрнәк сыйфатында бирелә.*

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Рп) х 100 | Рф - планнан тыш тикшерүләр саны (бер.)<br>Рп - планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен күрсәтмәләр саны (бер.) | | һәм шикаятьләр |
| 1.3. | Аларның нәтиҗәләре буенча шикаять бирелгән тикшерүләр өлеше | Ж х 100 / Пф | Ж - шикаятьләр саны (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны | 0% | |
| 1.4. | Нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган тикшерүләр өлеше | Пн х 100 / Пф | Пн - гамәлдә түгел дип танылган тикшерүләр саны (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 0% | |
| 1.5. | Милекче булмау һ. б. сәбәпле үткәрелмәгән планнан тыш тикшерүләр өлеше | По х 100 / Пф | По - тикшерелүче зат булмау сәбәпле үткәрелмәгән тикшерүләр (бер.)<br>Пф - үткәрелгән тикшерүләр саны (бер.) | 30% | |
| 1.6. | Планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында прокуратурага килештерүгә җибәрелгән, аларны килештерүдән баш тартылган гаризаларның өлеше | Кзо х 100 / Кпз | Кзо - аларны килештерүдән баш тарткан гаризалар саны (бер.)<br>Кпз - килештерүгә бирелгән гаризалар саны | 10% | |
| 1.7. | Нәтиҗәләре буенча материаллар карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрелгән тикшерүләр өлеше | Кнм х 100 / Квн | Кнм - вәкаләтле органнарга җибәрелгән материаллар саны (бер.)<br>Квн - ачыкланган тәртип бозулар саны (бер.) | 100 % | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.8. | Үткәрелгән профилактик чаралар саны | | | Данә | |
| **2.** | **Файдаланылган хезмәт ресурслары күләмен характерлаучы индикатив күрсәткечләр** | | | | |
| 2.1. | Штат берәмлекләре саны | | | Кеше | |
| 2.2. | Муниципаль контроль органы хезмәткәрләренә контроль чаралар йөкләнеше | Км / Кр= Нк | Км - контроль чаралар саны (бер.)<br>Кр - муниципаль контроль органы хезмәткәрләре саны (бер.)<br>Нк - 1 хезмәткәргә йөкләнеш (бер.) | | |